КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 июль г.Казань № 913

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 март, 129 нчы; 2021 ел, 24 май, 365 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1076 нчы; 2022 ел, 5 декабрь, 1286 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтага, 4 пунктның 2 графасындагы «кечкенә бияләйләр, башмаклар» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Бу карар 2023 елның 1 августыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин